ТЕРРИТОРИАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ
САБИНСКОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА РАЙОНЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел./ факс (84362) 2-40-66

**РЕШЕНИЕ**
**19 ноябрь 2018**

**КАРАР**
**№ 76/17**

# Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Шекше авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2018 нче ел 18 ноябренең Җирле референдум нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе күрсәткечләре нигезендә 2018 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде,аның буенча:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 634 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-603, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 95.11% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

референдумда катнашучыларның 574(95.19%) «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, Бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 процентган артыгын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашучыларның 29ы тавыш бирде, бу 4.81% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Саба районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1.2018 нче елның 18 нче ноябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны уздырылды, референдум нәтиҗәләре - гамәлдәге дип таныргa.

2."2019 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шекше авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300,00 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:

Шекше торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау

Алан-Елга торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау

Сәрдә торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау" кабул ителде дип санарга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Саба таңнары» газетасында бастырып чыгарырга яки Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба районы Шекше авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Саба районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе М.В.Галиуллин

Татарстан Республикасы
Саба районы
территориаль сайлау комиссиясе
секретаре К.Ф.Хисамиев